КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 апрель г.Казань № 345

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 7 март, 165 нче; 2019 ел, 17 май, 402 нче; 2019 ел, 13 июль, 572 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1006 нчы; 2020 ел, 18 февраль, 123 нче; 2020 ел, 27 апрель, 331 нче; 2020 ел, 9 июнь, 477 нче; 2020 ел, 24 июль, 622 нче; 2020 ел, 5 сентябрь, 790 нчы; 2020 ел, 21 ноябрь, 1042 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1230 нчы; 2021 ел, 14 май, 334 нче; 2021 ел, 30 июнь, 520 нче; 2021 ел, 17 август, 739 нчы; 2021 ел, 1 сентябрь, 803 нче, 2021 ел, 29 сентябрь, 927 нче, 2021 ел, 14 декабрь, 1229 нчы, 2021 ел, 30 декабрь, 1357 нче, 2022 ел, 24 февраль, 160 нчы, 2022 ел, 23 март, 259 нчы, 2022 ел, 7 апрель, 323 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тәлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында 9 пунктның 4 графасында «2» санын «1» санына, «5» санын «6» санына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

түбәндәге эчтәлектәге 11 пункт өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11. | «Сәләт - Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | | 1 | җиңел автомобиль | 17 010 | 70 |
| | | | 1 | микроавтобус/фургон | 30 375 | 125»; |

«Барлыгы» юлында «32» саннарын «34» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларга буйсынучы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга агымдагы норматив еллык чыгымнарга (ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларыннан тыш), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, муниципаль казна, бюджет, автоном учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга тәкъдим ителә торган норматив еллык чыгымнарга түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «BMW X5 xDrive 40i M Sport Pro | 303 740 | 6,55»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларга буйсынучы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга аларны йөртүчеләрдән башка файдаланганда, агымдагы норматив еллык чыгымнарга (ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларыннан тыш), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, муниципаль казна, бюджет, автоном учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга, аларны йөртүчеләрдән башка файдаланганда, тәкъдим ителә торган норматив еллык чыгымнарга түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «BMW X5 xDrive 40i M Sport Pro | 106 000 | 6,55». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин